**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.05.2026 **Чирмешән авылы** **№41**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының террорчылыкка һәм экстремизмга каршы мәгълүмати көрәш буенча эшче төркем төзү турында**

Иҗтимагый иминлекне тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен террорчылык актларыннан яклау, террорчылык һәм экстремизм идеологиясенә нәтиҗәле мәгълүмати каршы торуны оештыру максатларында, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Президентының «Террорчылыкка каршы көрәш чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 28 декабрендәге 1124 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясе, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршында террорчылыкка һәм экстремизмга мәгълүмати каршы тору буенча эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) төзергә.

1. Расларга:

1.1 Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә Эшче төркеме составы;

1.2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә Эшче төркем турында нигезләмә.

2. Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарының «Чирмешән муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршында пропаганда төркеме төзү турында» 2020 елның 16 июнендәге 62 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районы сайтында интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль
районы Башлыгы Р.Т.Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 4 маендагы
41 номерлы карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының террорчылыкка һәм экстремизмга каршы мәгълүмати көрәш буенча эшче төркем**
**СОСТАВЫ**

Эшче төркем рәисе:

Җамалетдинов Илнур Минсәгыйть улы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Эшче төркем рәисе урынбасары:

Муксинова Ләйләгөл Вәгыйз кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары

Гомәров Марат Шакир улы - «Татмедиа» АҖнең «Безнең Чирмешән» (Наш Черемшан) газетасы редакциясе» филиалы директоры – баш мөхәррире (килешү буенча)

Эшче төркем секретаре:

Галәүтдинова Эльвира Вәлирахман кызы – Чирмешән муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе

Эшче төркем әгъзалары:

Маркова Ольга Владимировна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;

Иляева Наталья Васильевна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» муниципаль учреждениесе башлыгы;

Галеева Ольга Николевна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль учреждениесе башлыгы;

Пешков Иван Николаевич – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чирмешән районы буенча бүлек башлыгы.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 4
маендагы 41 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының террорчылыкка һәм экстремизмга каршы мәгълүмати көрәш буенча эшче төркем турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе (алга таба – районның АТК) каршында төзелгән террорчылыкка һәм экстремизмга мәгълүмати каршы тору буенча эшче төркемнең (алга таба – эшче төркем) статусын, максатларын, бурычларын, функцияләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Эшче төркем муниципаль район территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында төзелгән даими эшләүче консультатив-координацион орган булып тора.

1.3. Үз эшчәнлегендә Эшче төркем Россия Федерациясе Конституциясенә, «Терроризмга каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Экстремистик эшчәнлеккә каршы көрәш турында» 25.07.2002 елгы 114-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, Террорчылыкка каршы милли комитет, Татарстан Республикасы АТК, Чирмешән муниципаль районы АТК карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Эшче төркемнең карарлары рекомендация характерында була һәм җирле үзидарәнең кызыксынган органнары, учреждениеләре һәм оешмалары тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.

2. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Эшче төркем эшчәнлегенең максаты булып җәмгыятьтә террорчылык һәм экстремизм идеологиясен тотрыклы кабул итмәүне формалаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшен координацияләү, шулай ук террорчылык һәм экстремизм юнәлешендәге күренешләргә оператив мәгълүмати җавап бирүне тәэмин итү тора.

2.2. Эшче төркемнең төп бурычлары булып тора:

район халкының яшь, социаль һәм мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә мәгълүмат сәясәтенең төп юнәлешләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

район территориясендә таратыла торган контрпропаганда һәм агарту материалларының нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм бәяләү;

җирле үзидарә органнарының эш планнары кысаларында террорчылыкка һәм экстремизмга мәгълүмати каршы тору чараларының еллык исемлеген төзү;

мәгариф, мәдәният, яшьләр һәм спорт учреждениеләре өчен профилактик чаралар үткәрү буенча методик тәкъдимнәр әзерләү;

экстремистик материаллар таралу фактлары яки террорчылык идеологиясе күренешләре ачыкланган очракларда оператив мәгълүмати җавап бирүне оештыру.

3. Функцияләр һәм вәкаләтләр

3.1. Йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарыннан, учреждениеләрдән һәм оешмалардан профилактика чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

эшкә хокук саклау органнары, эксперт җәмәгатьчелеге, дини оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итәргә (килешү буенча);

районның АТКсына террорчылыкка һәм экстремизмга каршы мәгълүмати көрәшне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

муниципаль учреждениеләрдә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында тарату өчен әзерләнгән мәгълүмати материалларны файдалануга яисә кире кагуга тәкъдим итәргә.

3.2. Эшче төркемнең эшчәнлеге «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 № 152-ФЗ Федераль законы һәм дәүләт һәм хезмәт серен саклау турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш гамәлгә ашырыла.

4. Эшчәнлекне оештыру

4.1. Эшче төркем составы Чирмешән муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

4.2. Эшче төркем утырышлары кирәк булганча, әмма кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш утырышлар район АТК рәисе инициативасы буенча яисә район АТК йөкләмәсе буенча чакырыла.

4.3. Утырышта эшче төркемнең расланган составының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы була. Карарлар ачык тавыш бирү юлы белән катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

4.4. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник яктан Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты тәэмин итә.

4.5. Эшче төркем секретаре утырышларның беркетмәләрен алып бара, утырышларны үткәрү вакыты һәм урыны турында 5 эш көненнән дә соңга калмыйча төркем әгъзаларына хәбәр итүне тәэмин итә, шулай ук кабул ителгән карарларны кызыксынган затларга 7 эш көне эчендә җибәрүне оештыра.

4.6. Эшче төркем әгъзалары аның эшендә үз вазыйфалары чикләрендә түләүсез нигездә катнашалар.

5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмә Район Башлыгы карары рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5.2. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Чирмешән муниципаль районы башлыгы карары белән кертелә.

Чирмешән муниципаль
районы башлыгы Р.Т. Айбатов